**Республика Татарстан**
**Кукморский Муниципальный район**
**СОВЕТ КОШКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районы**
**КУКШЕЛ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422115, Республика Татарстан, Кукморский район,
с. Кошкино, ул. Театральная, д.38
тел.: (84364) 31-2-35
эл. почта: Kosh.Kuk@tatar.ru

# РЕШЕНИЕ

«16» июнь 2025 ел №18

Күкшел авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Күкшел авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Күкшел авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә), Күкшел авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 октяберендәге 29 номерлы 2020 елның 21 декабрендәге 15 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 35 номерлы, 2024 елның 11

июнендәге 17 номерлы, 2024 елның 13 августындагы 25 номерлы, 2024 елның 03 декабрендәге 36 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 21 091,00 |

б) 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Айлык акчалата түләү 12 төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен нормативтан артмаган күләмдә түләнә – елына 15,48 айлык акчалата түләү.»;

в) 3.1 пунктның беренче абзацында «13990» санын «15389» санына алмаштырырга.

г) 3.5 пунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата түләү – хезмәт окладына карата 58 проценттан артмаган күләмдә.»

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Күкшел авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хәмидуллин